| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 17.12.2021 | Казан ш. | № 686-129/тэ-2021 |

«Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 № 405-65/тэ-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2022-2023 елларга җылылык энергиясе югалуны компенсацияләү максатында җылылык энергиясе сатып ала торган җылылык челтәрләре оешмаларына, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлеккә) 2022-2023 елларга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итүче, җылылык энергиясе сарыфларын

компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 11.12.2020 № 405-65/тэ-2020 карары кушымтасына, аны яңа редакциядә биреп (кушымтада бирелә), үзгәреш кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В. Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2020 № 405-65/тэ-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2021 № 686-129/тэ-2021
карары редакциясендә) кушымта

«Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылы белән тәэмин итүче оешмаларга, җылылык энергиясен югалтуларны компенсацияләү максаты белән җылылык энергиясе сатып алучы җылылык челтәрләре оешмаларына җиткерелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) 2021-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукцияләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Зеленодольск муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Осиново җылылык белән тәэмин итү компаниясе» ҖЧҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 578,55 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 596,77 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 596,77 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 633,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 633,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 650,37 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге